ӘДӘП ВӘ ӘХЛАК
КОРЪӘНИ КӘРИМНЕ УКУ ӘДӘПЛӘРЕ
→ 4 БИТ

ВӘГАЗЬ
РАҖӘБ АЕ – АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘ БӨЕКЛӘГӘН АЙ
→ 6 БИТ

ТАРИХИ МИРАС
ИДЕЛ БУЕНДА ИСЛАМ ДИНЕ
→ 10 БИТ

НӘСЫЙХӘТ
ЯУЛЫК – АЛЛАҺЫНЫҢ БҮЛӘГЕ
→ 12 БИТ

**ГЫЙНВАР, 2022**
№ 01 (318)


Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте басмасы

җөмәдәл-әүвәл – җөмәдәл-ахыр, 1443

# دين ومعيشت

# ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

12+



# Кулъязма Коръән әзерләнә

«Мөселман каллиграфының рухи максаты – шәмаил ясауда түгел, ә нәкъ менә Мосхаф Шәриф әзерләүдә...»

→ ДӘВАМЫ 8 НЧЕ БИТТӘ

ГАЗЕТАДА АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘНЕҢ ИСЕМНӘРЕ, КОРЪӘН АЯТЬЛӘРЕ БУЛГАНЛЫКТАН, БАСМАГА ИГЪТИБАРЛЫ БУЛЫГЫЗ!

# 1100 ЕЛЛЫККА БАГЫШЛАНГАН УТЫРЫШ УЗДЫ

## Татарстан мөфтие Нәзарәтнең 1100 еллык кысаларындагы башлангычлары хакында сөйләде

**12 гыйнвар көнне Казанда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов рәислегендә Идел буе Болгар дәүләтендә рәсми рәвештә Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына әзерләнү һәм аны үткәрү Республика оештыру комитетының киңәйтелгән утырышы узды. Утырышта Татарстан Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, РФ Президенты Администрациясенең Эчке сәясәт идарәсе башлыгы урынбасары Анатолий Вылегжанин, РФ мәдәният министры урынбасары, федераль оештыру комитетының җаваплы секретаре Ольга Ярилова, дәүләт һәм муниципаль хакимият органнары вәкилләре, мөфтиләр, үзәкләштерелгән дини оешмалар җитәкчеләре катнашты.**



Фото: dumrt.ru

Дин әһелләреннән беренче булып, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин чыгыш ясады. Ул иң әүвәл Татарстан өчен Идел буе Болгар дәүләтендә Исламның кабул ителүен билгеләп үтү – күркәм гадәт икәнлегенә басым ясады. 2010 елдан бирле 21 май көне республикада закон нигезендә истәлекле һәм бәйрәм көннәре исемлегенә кертелде. Моннан тыш, Исламны кабул итүнең 1100 еллыгын да тантаналы рәвештә үткәреп җибәрү өчен әзерлек эшләре берничә ел элек башланып киткән иде. Камил хәзрәт 2019 елда Дәүләт советына еллык юлламасында Татарстан Республикасы Президенты шундый бурычны куйганын искә алды һәм Рөстәм Нургали улына, республиканың оештыру комитетын үзенең җитәкчелеккә алганы өчен, рәхмәт әйтте.

Президентка тагын бер рәхмәтне Камил хәзрәт Рәсәй мөселманнары мәнфәгатьләрен яклаганы өчен җиткерде: «Миңа үткән елның ноябрь аенда Җиддәдә «Рәсәй – ислам дөньясы» стратегик караш төркеменең күчмә утырышында катнашырга насыйп булды. Рөстәм Нургали улының Согуд җитәкчелеге белән сөйләшүе безнең күз алдында булды. Рөстәм Нургали улы, без шаһит идек: Рәсәй мөселманнарының мәнфәгатьләрен сез бик зур ихласлык һәм сәяси осталык белән яклаган идегез ул чакта. Дөрес һәм үткен сүзләр табып, сез согудлеләрне үзегезнең якка күндерә белдегез. Рәсәйнең барлык мөселманнары исеменнән, бүгенге очрашуга җыелган мөфтиләр һәм башка мөселман дин әһелләре исеменнән зур рәхмәт сезгә», – дип мөрәҗәгать итте Камил хәзрәт Сәмигуллин.

Чыгышның төп темасына күчеп, мөфти: «1100 еллык режимына Нәзарәт 2021 ел башыннан керде, һәм башкарып өлгергән эшчәнлекнең расланган проектларны гамәлгә ашыру өчен нигез булды», – дип белдерде. Мисалга ул гыйнвар аеның беренче көннәрендә узган Рәсәйкүләм мөселман форумын китерде. Җыен үзенә күрә Итил елгасында Рәсәй мөселманнары корылтае рәвешендә уңышлы үтте һәм быел Рәсәйкүләм мөселман яшьләре форумын оештыру өчен яхшы тәҗрибә булды.

Гамәлгә ашырылган чираттагы зур проект буларак, мөфти татар телендә эшли торган онлайн-мәдрәсә ачуны атады һәм аның бер еллык нәтиҗәләре белән таныштырды, аның быел рус телендә дә эшли башлаячагы хакында җиткерде. Аннары ул «Кол Шәриф» мәчетендә Нәзарәтнең яңа проектына старт бирелүенә – Коръәннең кулъязма мосхафын язу тантаналы рәвештә башлануга, «Ибне Фадлан» фильмы төшерү эшләре алып барылуга, «Даруль-кутуб» электрон китапханәсен үстерүгә тукталды. 2022 елда Рәсәй дини мирасы сериясеннән китаплар чыгарылачагын, социаль роликлар һәм программалар төшереләчәген әйтте.

Шулай ук утырышта катнашучыларга Татарстан мөфтие урынбасары, Нәзарәтнең «Хозур» нәшрияты җитәкчесе Ришат Хәмидуллин Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул ителүнең 1100 еллыгын бәйрәм итү логотипы проектын тәкъдим итте. Рөстәм Миңнеханов логотипны хупларга һәм аны федераль оештыру комитеты каравына кертергә тәкъдим ясады.

**dumrt.ru** сайтыннан

922-2022
Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы

Фото: dumrt.ru

# ИСЛАМНЫ КАБУЛ ИТҮНЕҢ 1100 ЕЛЛЫГЫ ЛОГОТИБЫ ТӘКЪДИМ ИТЕЛДЕ

КАЗАНДА УЗГАН ИДЕЛ БУЕ БОЛГАР ДӘҮЛӘТЕНДӘ РӘСМИ РӘВЕШТӘ ИСЛАМ ДИНЕН КАБУЛ ИТҮНЕҢ 1100 ЕЛЛЫГЫНА ӘЗЕРЛӘНҮ ҺӘМ АНЫ ҮТКӘРҮ РЕСПУБЛИКА ОЕШТЫРУ КОМИТЕТЫ УТЫРЫШЫ УЗДЫ

Утырыш Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов рәислегендә узды. Аның эшендә шулай ук Рәсәй Федерациясе Президенты Администрациясенең Эчке сәясәт идарәсе башлыгы урынбасары Анатолий Вылегжанин, Рәсәй Федерациясе Мәдәният министры урынбасары, федераль оештыру комитетының җаваплы секретаре Ольга Ярилова, Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, мөфтинең мәгълүмати сәясәт буенча урынбасары, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хозур» нәшрият йорты генераль директоры Ришат Хәмидуллин, мөфтинең мәгариф буенча урынбасары, КИИ һәм РИУ ректоры, Рәсәй Ислам мәгарифе советы рәисе Рафикъ Мөхәммәтшин, дәүләт хакимияте вәкилләре, фәнни җәмәгатьчелек, Рәсәйнең 12 төбәгеннән мөфтиләр һәм мөфтият вәкилләре катнашты.

Татарстан мөфтиенең мәгълүмати сәясәт буенча урынбасары, Нәзарәтнең «Хозур» нәшрият йорты генераль директоры Ришат Хәмидуллин утырышта катнашучылар игътибарына 1100 еллык логотибын тәкъдим итте. Ул билгеләп үткәнчә, логотипны эшләүчеләр алдында Рәсәйнең үз җирлегендә Ислам үсешенең бай һәм борынгы тарихын һәм аның мөселман дөньясының мөһим өлеше булуын графика ярдәмендә күрсәтү бурычы торган.

Логотип 5 график элементтан тора, аның ярдәмендә борынгы Болгар шәһәре һәм ислам дине символларын бик җиңел танып алырга мөмкин. Болар:

**1. Болгардагы Истәлек билгесе силуэты.** Борынгы шәһәрнең әлеге үзенчәлекле бинасы мәчетне хәтерләтә һәм ул болгар архитектурасы стилендә эшләнгән, Идел буенда мөселман мәдәнияте барлыкка килүнең визуаль чагылышы булып тора. Бина 2011 елда рәсми рәвештә ислам динен кабул итү хөрмәтенә төзелде. Истәлек билгесе бабаларыбыз тарафыннан ислам динен сайлауга хөрмәт һәм рәхмәт белдерү булып һәм традицияләрнең дәвамлылыгын күрсәтә.

**2. Ачылган китап – Коръән.** Ул – Исламның нигезе, Аллаһы Тәгаләнең сүзе, бар кешелеккә иңдерелгән могҗиза, тирән белемнәр һәм кыйммәтләр чыганагы. Изге Китапка карата булган әдәп буенча, Коръәнне бер сәбәпсез ачык калдыру тыелган. Шуңа күрә логотипта ачылган Коръән мөселманнарның Аллаһы кушкан әмерләрне үтәргә, Аның ризалыгына ирешергә омтылуларын ассызыклый.

**3. Лалә чәчәге.** Аның таҗлары гарәп графикасында «Аллаһы» сүзенә охшаш булган язылышны хәтерләтә, ул мөселман мәдәниятендә яңарыш һәм үсеш символын гәүдәләндерә. Бер үк вакытта лалә – татар халкының матур бизәге, ул традицион чигү эшләрендә кулланылган һәм шулай ук мәчетләрнең эчке бизәлешендә очрый торган иң популяр элементларның берсе. Гасырлар дәвамында лалә яңа мәгънәләр белән тулылана. Дини эчтәлеккә дә яңа аңлатма өстәлә: лалә бөек казанышларга омтылышны гәүдәләндерә башлый. Шулай ук чәчәк Республикабызның үсешкә омтылуын символлаштырып, аның гербында да урын алган.

**4. «1100» сүзе рус һәм гарәп телләрендә язу кагыйдәләре буенча эшләнгән.** Язма структур яктан лалә һәм Коръән белән бәйле.

**5. «Болгар» сүзенең гарәп телендә язылышы бирелгән.**

Югары телгә алынган элементлар җыелмасы Борынгы Болгарда башлангыч алган Идел буе мөселманнарының 1100 еллык Коръән традицияләре үсешен гәүдәләндерә.

– Логотип шулай ук төрле төстә һәм форматларда күркәм күренергә тиеш. Ул төсле вариантта да, монохромда да уңышлы күренергә тиеш; зур күләмдә дә, кечкенә күләмдә дә төгәл һәм аңлаешлы булырга тиеш, – дип ассызыклады Ришат Хәмидуллин.

Логотипны билге һәм блок рәвешендә кулланырга мөмкин: ягъни билге астындагы язу белән һәм язусыз. Логотипның татар телле варианты да бар.

Утырыш вакытында экраннарда төрле материалларда һәм яссылыкларда логотип төшерү вариантлары күрсәтелде. Логотип тире һәм агач кебек материалларда, урам өслекләрендә, полиграфия һәм сувенир продукциясендә, басма һәм электрон массакүләм мәгълүмат чараларында күзгә ташланып торырлык итеп күренә. Аның сызымнарын саклаган хәлдә зурайтырга яки кечерәйтергә, текстны төрле телләрдә кулланырга мөмкин.

**dumrt.ru** сайтыннан

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
№ 01 (318) гыйнвар, 2022 | җөмәдәл-әүвәл – җөмәдәл-ахыр, 1443




Фото: shutterstock.com

# Коръәни Кәримне уку әдәпләре

**Хакыйкатьтә, кешеләр арасында Коръәнне гәҗит сыман укучылар вә аның мөкатдәслеген аңлап бетермәүчеләр бар! Коръәни Кәрим Аллаһының мөкатдәс вә мөбарәк сүзләре булу сәбәпле, аны кадерләп тоту һәм хөрмәт итү тиешле. Мөселманнар өчен аннан да кадерлерәк Китап юк, шуның өчен дә, алар Коръәни Кәримгә генә хас булган әдәпләрне сакларга тырышалар. Бу әдәпләр ике төргә: тышкы һәм эчке (калби) әдәпләргә бүленә.**

### КОРЪӘНИ КӘРИМНЕ УКЫГАНДА ҮТӘЛЕРГӘ ТИЕШЛЕ ТЫШКЫ ӘДӘПЛӘР

1. Коръәни Кәримне укучының тәне госел-тәһарәтле, киеме чиста һәм гаурәте каплаган булырга тиеш. Аллаһы Раббыбыз Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

*«Пакьләнгәннәр генә аңа кагыла ала».*

*«Әл-Вакыйга», 56:79*

2. Тешләрне һәм авызны мисвәк белән пакьләү. Сүз һәм аваз чыга торган урын булганга без аны Аллаһы ризалыгы өчен чистартабыз, шул рәвешле Коръәни Кәримне олуглыйбыз.
3. Коръәни Кәримне мөмкин кадәр кыйблага юнәлеп уку.
4. Төрле шөгыльләр, эшләр комачау итәргә тиеш түгел.
5. Коръәни Кәримне уку алдыннан «Әгуүҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим», дип башлау.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

*«[Расүлем!] Коръән укыган чагыңда ләгънәтле шәйтаннан Аллаһыга сыен».*

*«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:98*

Ягъни «Әгуүҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим», дип әйт.

6. «Әт-Тәүбә» сүрәсеннән кала һәр сүрә башында «Бисмилләһ»не әйтү кирәк.
7. Коръәни Кәримне тәҗвид кагыйдәләренә нигезләнеп, тыныч тавыш белән уку. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

*«Яки аңа өстә [һәм өчтән ике-сен гыйбадәттә үткәр]. Коръәнне тәртил белән [әкрен-әкрен, ачык итеп] укы».*

*«Әл-Мүзәммил / Чорналган», 73:4*

8. Коръәни Кәримне тәртибе белән уку, ягъни сүрәләрнең һәм аятьләрнең тәртибен саклап уку.
9. Укый башлаган сүрәне ахырына кадәр укып тәмамлау.
10. Коръәни Кәримгә хөрмәт йөзеннән, аның мосхафын, ягъни гарәпчәсен яткан хәлдә укымау. Ә менә яттан белгән сүрә яки аятьләрне яткан көе укуның гаебе юк.
11. Кеше мөрәҗәгатьләренә бүленмәү. Сәлам бирсәләр, сәламне кайтарып Коръәни Кәримне укуны дәвам итү.
12. Яттан укыганчы мосхафка карап уку, чөнки Коръән аятьләренә карау – гыйбадәт (Искәрмә: намазда мосхафка карап уку ярамый).
13. Коръәни Кәримне матур тавыш белән көйләп уку. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә болай дип әйткән: «Коръәни Кәримне гарәп мәкаме белән, әдәби һәм олуглык ияләренең телендә укыгыз. Дөреслектә, миннән соң шундый кавемнәр килер, алар насараларга охшатып җырлап көйләрләр».
14. Сәҗдә аятьләре килсә, тиләвәт сәҗдәсе кылу.
15. Коръәни Кәримне укыганда еларга һәм хошугъ халәтендә булырга тырышу.
16. Каты тавыш белән укымыйча, пышылдап уку – мөстәхәб. Мәгәр Коръәни Кәримне өйрәнү-укыту ниятеннән кала.

### КОРЪӘНИ КӘРИМНЕ УКЫГАНДА ЭЧКЕ (КАЛБИ) ӘДӘПЛӘР

1. Коръәни Кәримне бирелеп, мәгънәсенә төшенергә тырышып, фикерләп уку, һәм аның белән гамәл кылырга тырышу. Раббыбыз Аллаһы Үзенең Изге Китабында болай дип әйтә:

*«[Коръәни Кәрим] Мөбарәк бер Китап ки, аны синә алар аның аятьләре хакында уйласыннар һәм [нәфесләренең бозык теләкләреннән арынган] аек акылга ия булганнар үгетләнсен дип иңдердек».*

*«Сад», 38:29*

2. Коръәни Кәримне укыганда бу кеше сүзе түгел, Аллаһы сүзе икәнлеген истә тотып уку.
3. Коръәни Кәримне төп максатын белеп уку, ягъни бу Китап савапка ирешер һәм гыйбрәт алыр өчен укыла.
4. «Мин инде Коръәни Кәримне шәп укыйм», дип масаймау, тәкәбберләнмәү, бәлки киресенчә, түбәнчелек белән укып, нәфесеңне тәрбияләү.
5. Коръәни Кәримне укыган кешене тыңлаганда яисә ишеткәндә, сөйләшмәү, игътибар белән тыңлап, калеб белән фикерләү. Коръәни Кәримдә Хак Тәгалә болай дип әйтә:

*«Коръән укылган чакта, аны тыңлагыз һәм дәшми торыгыз, – бәлки, сез [Аллаһы тарафыннан] рәхмәт ителерсез».*

*«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:204*

6. Коръәннән булдыра алган хәтле ятлау һәм ятлаганын онытудан саклану, чөнки Коръәни Кәримне ятлау – сөннәт гамәл, ә ятлаганыңны онытмау – вәҗиб.
7. Коръәни Кәримне укыганнан соң дога кылу.

***Йә, Раббым, безне Синең Изге Китабыңны укучылардан, аның белән гамәл кылып, аның аятьләре хакында фикерләүчеләрдән итсәң иде. Йә, Раббым, укыган аятьләребез, сүрәләребез ихласлыкларыбызны ныгытып, ике дөнья бәхетенә ирешүдә сәбәпче булса иде. Әмин!***

**«Тимергали хәзрәт вәгазьләре»** *китабыннан*

**МӨФТИ КАМИЛ ХӘЗРӘТ СӘМИГУЛЛИННЫҢ МӘКАЛӘЛӘР ЦИКЛЫ**

# «ПӘЙГАМБӘРЛӘР КЫЙССАСЫ»

ДИП АТАЛГАН ЯЗМАЛАР СЕРИЯСЕ



Фото: dumrt.ru

# ТАУ КУЫШЫ КЕШЕЛӘРЕ КЫЙССАСЫ

«Әл-Кәһф» – Коръәни Кәримнең унсигезенче сүрәсе. Ул пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә Мәккә чорында иңгән. Әлеге сүрә 110 аятьтән тора. Анда тугызынчы аятьтән алып, егерме алтынчы аятькә кадәр, «әсхабел-кәһф» кешеләре турында сөйләнә. Алар явыз хәкимнең эзәрлекләвеннән мәгарәгә качып йокыга талалар һәм шул халәттә тау куышында өч йөз елдан артык булганнан соң, яңадан тереләләр. Әлеге мәгарә әһелләренең яңадан терелүе Аллаһы Тәгаләнең кодрәтенраслый торган билге булып тора. Фикер йөртүчеләр өчен әлеге кыйссада күпләгән гыйбрәтле мисаллар һәм үгет-нәсыйхәтләр бар. Аллаһы Тәгалә Үзе үк Коръәни Кәримдә безгә болай дип әйтә:

*«Без сиңа аларның башыннан кичкәннәрне хак белән сөйлибез. Һичшиксез, алар Раббыларына иман китергән яшьләр иде. Без аларның һидаятьләрен арттырдык».*

*«Әл-Кәһф / Мәгарә», 18:13*

Мәгълүм булганча, Гайсә пәйгамбәр галәйһиссәлам күккә ашканнан соң, кешелек дөньясы берничә гасыр буе «пәйгамбәрсез» чорда яшәгән була. Бу дәвердә халык Инҗилнең эчтәлегенә үзгәрешләр керткән һәм гөнаһ баткаклыгына чумган, хакимнәр кешеләрне потларга табынырга һәм аларга корбан чалырга мәҗбүр иткән. Шундый хөкемдарларның берсе булып Дикьянус саналган. Ул бөтен дәүләт буенча йөреп, табигъларының диндарлыгы турында турыдан-туры мәгълүмат җыя торган булган. Иман әһелләре ул идарә иткән дәвердә яшерен рәвештә Аллаһыга табынганнар һәм гыйбадәт кылганнар. Әмма тотылган очракта, мөэминнәргә Дикьянус алдында икенең берсен сайларга туры килгән: үлем яки ширек кылу. Иман әһелләренең күбесе үзләре өчен һәлак булуны кулай күргән. Шуңа күрә үлем бәрабәренә алар Аллаһыга иманнарын саклап калып, җәннәтне сайлаганнар.

Иман китерүчеләр арасында берничә яшь егет – хөкемдарга якын мөнәсәбәттә торган гаиләләрдән чыккан балалар да булган. Моны белеп, Дикьянус яшьләрне кулга алырга һәм аның янына китерергә боерган.

Аларны күреп, ул болай дип әйткән:

– Сезгә әлеге потларга табынырга һәм аларга багышлап корбан чалырга нәрсә комачаулый? Ни өчен сез бу шәһәрдә яшәүчеләрдән үрнәк алмыйсыз? Сез, башкалар кебек үк, безнең илаһларга табына һәм аларга корбан чала башлаячаксыз, яки үлемгә дучар ителәчәксез.

Әмма бу яшьләр аңа үзләренең иманнары турында ачыктан-ачык белдергәннәр:

*«Алар [ул залим хөкемдарның потларга сәҗдә кылдыруына каршы] аягөсте торып баскач, Без аларның күңелләренә куәт [һәм сабырлык] бирдек, шул сәбәпле алар әйттеләр: «[Потлар безнең Раббыбыз була алмый!] Безнең Раббыбыз – күкләрнең һәм җирнең Раббысы [булган Аллаһы Тәгалә]. Без Аннан башканы илаһ дип әйтмибез. Юкса, [дөреслектән] ерак сүз әйткән булырбыз. Безнең [ялгыш юлда булган] кавемебез Аннан башка илаһлар сайлады. Алар хакында ачык бер дәлил китерсәләр иде! [Ширек кушу белән] Аллаһыга карата ялган уйдырма чыгарудан да залимрәк кем бар?»*

*«Әл-Кәһф / Мәгарә», 18:14-15*

Шул рәвешчә, ачыктан-ачык каршылык белдерүче шушы яшьләргә ачуы чыккан Дикьянус аларга уйлар өчен вакыт биргән һәм бер илаһлыктан баш тартып, гомерләрен саклап калырга тәкъдим иткән. Әмма үткен егетләр, Аллаһыга тәвәккәлләп, сарайдан качып чыгып киткәннәр һәм шәһәрдән ерак түгел генә урнашкан тау куышына яшеренгәннәр.

Мәгарәгә бару юлында алар Кафештатайуш исемле көтүчене очратканнар. Ул ислам динен кабул иткән һәм аларга җиденче булып ияргән. Бу көтүченең Кытмир кушаматлы гадел эте булган. Бу хәерле җан иясе алар артыннан бер дә калмыйча ияреп барган һәм җәннәткә дә алар артыннан барып эләккән. Әгәр җәннәткә Аллаһының дусларына ияргән эт тә керә алгач, Аллаһы Аның дусларына иярүчеләрне җәннәткә кертми димени?!

Һичшиксез, тау куышында яшәүчеләрнең бу батыр гамәле Аллаһы Тәгаләнең мактавына лаек. Үз диннәрен саклап калу өчен, алар туган йортларын һәм бай әти-әниләрен ташлап, яшьтәшләре кебек дандәрәҗә, шөһрәткә бирелү юлына басмыйлар. Киресенчә, җәмгыятьтә зур абруй казанган аталары канаты астында гамьсез тормыш рәвеше алып баруга караганда, алар Аллаһыга табынып аулак яшәүне өстенрәк күргәннәр.

Шулай итеп, егетләр мәгарәгә кергәннәр. Юлдан алҗып, алар түзә алмаслык бер арыганлык сизеп, йокыга киткәннәр. Өч йөз тугыз ел дәвам иткән бу йокыны аларга Аллаһы җибәргән. Тәннәренә зыян килмәсен өчен, Яратучы аларны вакыт-вакыт бер яктан икенче якка борып куйган. Эт тә, алгы тәпиләрен сузып, мәгарәгә керү ишеге алдында йоклаган.

*(Дәвамы киләсе санда)*


Фото: shutterstock.com

Бу кичәләрдә мөселманнар Раббылары һәм тормышлары турында уйланалар, фикер йөртәләр, Коръәнне күп итеп укыйлар, догалар кылалар.

# Раҗәб ае – Аллаһы Тәгалә бөекләгән ай

**Барча галәмнәрнең Раббысы, Тәрбиячесе, Яратучысы булган Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә барча хәмед-сәналәребез ирешсен. Шулай ук йөрәкләребезнең иң нечкә җирләреннән шытып чыккан салават-шәрифәләребез юлбашчыбыз, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә ирешсен. Аллаһы Тәгалә барчабызга да күңелләребездәге изге ният, морад-максатларыбызга ирешергә, күңелләребездә булган барча начар сыйфатларыбыздан арынырга насыйп итсен. Безләрнең бүгенге көнебезне кичәгеләреннән, иртәгесе көннәребезне бүгенгесеннән хәерлерәк кылса иде.**

Хөрмәтле дин кардәшләрем, бүгенге мәүгыйзәбез – «Раҗәб ае – Аллаһы Тәгалә бөекләгән ай» дип атала. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәзрәтләре бер хәдистә: «Раҗәб – Аллаһының ае, шәгъбан – минем аем, ә Рамазан – өммәтемнең ае», – дип әйткән. Берәү Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән: «Йә, Расүлуллаһ, ни өчен раҗәб Аллаһы ае соң ул?» – дип сораган. Расүли Әкрам салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Бу айда чын күңелдән тәүбә итүчеләргә Аллаһы Тәгаләнең мәгъфирәте иңә, бу айда сугышлар тыелган, бу айда Аллаһы Тәгалә бөтен пәйгамбәрләрнең догаларын кабул кылган һәм күп кенә әүлияларны (изгеләрне) дошман кулларыннан коткарган», – дип аңлаткан. Раҗәб аенда кылган изге гамәл-гыйбадәтләр өчен Аллаһы Раббыбыз савапларны арттырып бирә, шул сәбәпле, изгелекләрне күбрәк кылу бик тә әһәмиятледер. Бу форсатны кулланган кешеләр – уңыш казанучылар һәм чын алыш-биреш кыйммәтенә төшенүчеләр.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәзрәтләре раҗәб аеның беренче җомгасына каршы булган кичтә уяу булырга киңәш иткән. Фәрештәләр аны Рәгаиб кичәсе дип атаганнар. Күп гасырлар дәвамында мөселманнар бу кичәгә зур әһәмият бирәләр. Әлеге кичәдә догалар кабул була. Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм икенче бер хәдисендә болай дип әйткән: «Биш кичәдә Аллаһы Тәгалә Үз колларының үтенечләрен кабул кылыр: Рәгаиб, Бәраәт, Җомга киче, Рамазан һәм Корбан гаетенә каршы кичәләр». Ошбу кичәләр белән бүләкләнгән ай гади буламы? Догалары кабул кылыначак кеше бәхет ачкычы тоткан кешедәй түгелме, кардәшләрем?

Бу кичәләрдә мөселманнар Раббылары һәм тормышлары турында уйланалар, фикер йөртәләр, Коръәнне күп итеп укыйлар, догалар кылалар. Аллаһы Тәгалә безгә гөнаһлардан пакьләнергә, изге ниятләребезгә, максатларыбызга ирешергә зур мөмкинлекләр бирә. Без шушы фазыйләтләргә игътибарлырак булырга, аларны шатланып, сөенеп каршы алырга тиешбез.

Нинди көн соң ул Рәгаиб кичәсе? Бу – сөекле Пәйгамбәребезнең әтисе хәзрәти Габдулла белән әнисе Вәһеб кызы хәзрәти Әминәнең никахлашкан көннәре. Әле ул гына түгел, раҗәб ае тагын бер мөбарәк кичә белән бизәкләнгән – ул Мигъраҗ кичәсе. Мигъраҗ кичәсе раҗәб аеның 26 нчы көненнән 27сенә каршы кичтә була.

Әйе, ошбу изге вакыйга да раҗәб аенда була. Моңа дәлил Коръәннең әлеге аятендә китерелә:

*«Аятьләребездән кайберләрен күрсәтик дип, бер төнне [бик кыска бер вакытта Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм колын Харам мәчетеннән [алып] Без тирә-ягын бәрәкәтле иткән Әкъса мәчетенә күчерүче [булган Аллаһы нииндидер бер урында булудан һәм бөек Затына килешми торган төрле түбән сыйфатлардан ерак һәм бөтен] кимчелекләрдән пакь. Һичшиксез, Ул – [һәрнәрсәне] Ишетүче, Күрүче».*

*«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:1*

Нәтиҗә булып, ошбу кичәдә:

– биш вакыт намаз фарыз кылына;

– «Әл-Бәкара» сүрәсенең ахыргы аятьләре иңә (285-286 нчы аятьләр);

– Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә Кыямәт көнендә өммәтен яклау хокукы бирелә, ягъни Пәйгамбәребез Кыямәт көнендә гөнаһлы мөселманнар өчен Аллаһы каршында шәфәгать итәчәк.

Мөхтәрәм дин кардәшләрем! Ошбу олы фазыйләтләре булган айдан да файда алып, Аллаһының ризалыгына ирешергә омтылмасак, гафилләрдән булуыбыз ихтимал.

Аллаһы Раббыбыз ошбу вәгазьләребездән разый булсын. Аларны файдаланырга, күңелләребездәге барча начар сыйфатлардан арынырга насыйп әйләсен. Чын мәгънәсендә мөселман кешесе булып яшәргә, вә чын мәгънәсендә мөселман кешесе булып Аллаһы Раббыбыз хозурына күчәргә насыйп итсен. Әмин.

**Динар ЗЫЯТДИНОВ,**
ТР МДНнең «Зәкят» хәйрия фонды хезмәткәре

# Пәйгамбәребез кылган догалар

**Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең һәр гамәле, сүзе безнең өчен үрнәк булып тора. Әгәр бу догаларны өйрәнеп, аларны тормышыбызга кертеп җибәрсәк, Аллаһының рәхмәте белән, шул догалар бәрәкәтендә яшәрбез, чөнки бу догаларның фазыйләте бик зур.**



Фото: shutterstock.com

*Әлеге догалар арасында Пәйгамбәребез билгеле бер вакыйгадан соң кылганнары да, башка кеше килеп, дога өйрәтүен сораганнан соң, укып күрсәткәннәре дә бар. Кайбер зикерләрне Расүлебез көненә билгеле бер санда әйтүенең күркәмлеген хәбәр иткән. Расүлебез, мәсәлән, көнгә йөз мәртәбә "Сүбхәәнәллааһи вә бихәмдиһ" сүзләрен әйткән кешенең гөнаһлары, диңгез күбеге кадәр күп булса да, гафу ителәр, дип әйтеп калдырган.*

**«РАББӘНӘ» ДОГАСЫ:**

رَبَّنَا آتِنَا فِى الدُّنْيَا حَسَنَةً وَفِى الْآخِرَةِ حَسَنَةً وَقِنَا عَذَابَ النَّارِ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ

**Раббәнәә әәтинәә фид-дүнйәә хәсәнәтән вә фил-әәхырати хәсәнәтән вә кыйнәә гәҙәәбән-нәәр. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиин.**

Мәгънәсе: *«Йә Раббым! Безгә дөньяда да, Ахирәттә дә изге хәлләрне насыйп ит. Шулай ук безне җәһәннәм газабыннан сакла! Әй Рәхмәтле Аллаһы! Бөтен нәрсә Синең рәхмәтеңдә».*

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән риваять ителгәнчә, Пәйгамбәребез болай дип боерган: «Кем көнгә йөз мәртәбә:

لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ وحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ لَهُ المُلْكُ ولَهُ الحَمْدُ وهُوَ عَلَى كُلِّ شَيٍ قَدِيرٌ

**«Ләә иләәһә илләлааһү вәхдәһү ләә шәриикә ләһ, ләһүл-мүлкү вә ләһүл-хәмдү вә һүә галәә күлли шәй-иң кадиир».**

Мәгънәсе: *«Аллаһыдан башка илаһ юк. Аның дусты һәм охшашы юк. Мөлкәт – Аныкы, мактау да Аңа хастыр. Аның һәрнәрсәгә көче җитә»,* – дисә, бу зикер аның өчен ун кол азат итү савабына тиң булыр, аңа йөз савап языла, йөз гөнаһы кичерелер, ул көн кичкә кадәр шәйтанның явызлыгыннан имин булыр һәм һичкем аның бу догасыннан артыграк дога укый алмас», – дигән.

Кем көнгә йөз мәртәбә:

سُبْحَانَ اللَّهِ وَبِحَمْدِهِ

**«Сүбхәәнәллааһи вә бихәмдиһ»** *«Аллаһыны мактап тәсбих әйтәмен»*, – дисә, ул кешенең гөнаһлары диңгез күбеге кадәр күп булса да, бетәр», – дигән пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм.

Беркөнне бер бәдәви пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә килеп: "Йә Расүлуллаһ! Миңа һәрвакыт укый торган бер дога өйрәт", – дигән. Аллаһының Расүле аңа:

لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ وحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ اللَّهُ اكْبَرُ كَبِيرًا وَلْحَمْدُ لِلَّهِ كَثِيرَ سُبْحَانَ اللَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ لَا حَوْلَ وَلَا قُوَّةَ إِلَّا بِاللَّهِ الْعَزِيزِ الْحَكِيمُ

**«Ләә иләәһә илләллааһү вәхдәһү ләә шәриикә ләһ. Аллааһү әкбәру кәбииракә. Вәлхәмду лилләәһи кәҫииракә. Сүбхәәнәллааһи раббил-гааләмиин. Ләә хәүлә вә ләә куввәтә илләә билләәһил-газиизил-хәкиим».**

Мәгънәсе: *«Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы һәрнәрсәдән бөек. Аңа күпсанлы мактаулар булсын. Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһыны тәсбих итәмен. Газиз һәм Хаким булган Аллаһыдан башка көч һәм куәт иясе юктыр»,* – дигән.

Бәдәви: "Әй Аллаһының Расүле! Бу Аллаһы өчендер, минем өчен бер нәрсә юкмы?" – дип сораган. Моңа Пәйгамбәребез:

اَللَّهُمَّ اغْفِرْ لِي وَارْحَمْنِي وَاهْدِنِي وَارْزُقْنِي

**«Аллааһүммә-гъфир лии вәрхәмнии вәһдиинии вәрзүкъний».**

*«Аллаһым! Минем гөнаһларымны кичер, миңа мәрхәмәт ит, мине кызган һәм ризыкландыр»,* – дип дога кыл, – дигән.

Әбү Һөрайра Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең болай дип дога кылуын риваять иткән:

اَللَّهُمَّ اَصْلِحْ لِي دِينِي الَّذِي هُوَ عِصْمَةُ أَمْرِي وَ اَصْلِحْ لِي دُنْيَايَ الَّتِي فِيهَا مَعَاشِي وَ اَصْلِحْ لِي أَخِرَتِي الَّتِي فِيهَا مَعَادِي وَاجْعَلِ الْحَيَاةِ زِيَادَةً لِي فِي كُلِّ خَيْرٍ وَاجْعَلِ الْمَوْتَ رَاحَةً لِي مِنْ كُلِّ شَرٍّ

**«Аллааһүммә әсълих лии диинийәл-ләҙии һүә гыйсъмәтү әмрии вә әсълих лии дүньйәйәл-ләтии фииһәә мәгаашии вә әсълих лии әәхыйратийәл-ләтии фииһәә мәгаадии вәҗгалил-хәйәәти зийәәдәтән лии фии күлли хайрин вәҗгалил-мәүтә раахәтән лии мин күлли шәррин».**

Мәгънәсе: *«Аллаһым! Һәр эшемне саклаучы булган динем белән мине котылуга ирештер. Эчендә яшәгән, тормышымны тәэмин иткән дөньямны минем өчен хәерле кыл. Кайту урыным булган Ахирәтемне дә минем өчен хәерле нәрсәләр белән тулы бер урын әйлә. Үлемне дә минем өчен бөтен начарлыклардан котыла торган рәхәтлек итеп кыл».*

Сәхифәне **Айсылу ЮЛДАШЕВА** әзерләде

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
№ 01 (318) гыйнвар, 2022 | җөмәдәл-әүвәл – җөмәдәл-ахыр, 1443



Фото: dumrt.ru

# Нәзарәт Коръәннең кулъязма мосхафын язуга керәште

**12 гыйнварда Казанның «Кол Шәриф» мәчетендә Рәсәй мөфтиләре һәм дин әһелләренең күз алдында Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең яңа проектына старт бирелде – Коръәннең кулъязма мосхафын язу тантаналы рәвештә башланып китте. Әлеге чара Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен рәсми кабул итүгә 1100 ел тулуга әзерлек һәм бәйрәм итү буенча республика оештыру комитеты утырышы кысаларында үткәрелде.**

Бу вакыйга күпсанлы кунаклар – Оештыру комитеты утырышында катнашучылар, мөфтиләр, Рәсәйнең танылган мөселман дин әһелләре, хакимият органнары, фәнни җәмәгатьчелек һәм ММЧ вәкилләре катнашында узды.

– Коръән белән бәйле бар нәрсә үзеннән-үзе бөек була. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә Коръән бирелә һәм ул барлык пәйгамбәрләрнең иң сөеклесенә әверелә. Җәбраил галәйһиссәлам Коръән белән килгән, фәрештәләрнең башлыгына әверелгән. Коръән Рамазан аенда иңдерелә һәм ул барлык айларның солтанына әйләнә. Коръән Кадер кичәсендә иңә һәм ул барлык төннәрнең иң яхшысына әйләнә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Сезнең иң яхшыгыз шулдыр ки, кайсыларыгыз Коръән өйрәнде һәм аны башкаларга өйрәтте». Коръәнне аңлау өчен башка китаплар укыла. Без гомеребез дәвамында барлык китапларны бары бердәнбер Китапны – Коръәнне өйрәнү өчен укыйбыз, – дип башлады Камил хәзрәт.

Проектны кунакларга ул үзе тәкъдим итте. Хәзрәт Рәсәйдә, аерым алганда Идел буенда, каллиграфия мәктәбенең бик бай тарихка ия булуы, 1917 елгы революциягә кадәр аның бик көчле эшләве, ләкин җуелуы хакында әйтте. Шул ук вакытта Рәсәй мөселманнарының Коръәнне әзерләп бастыру тарихы һәм традицияләре дә бар. Бу, иң беренче чиратта, 1803 елда Казанда Коръәннең «Казан басмасы» чыгуы һәм аны камилләштерү буенча галимнәр арасында күптөрле бәхәс-тәкъдимнәр булуы белән бәйле. Әлеге гыйльми бәхәсләр тулы бер методология булып калыплаша. Моңа дәлил булып Муса Бигиевнең «Тасхих ресми хат» һәм Шиһабетдин Мәрҗанинең «Фәваид әл-Мүһиммә» хезмәтләре тора. Нәзарәтнең кулъязма мосхафы татар мөселманнарының шушы ике зур онытылган, әмма торгызылырга тиешле казанышын – каллиграфия мәктәбен һәм Коръәнне әзерләү традицияләрен кайтаруга юнәлтелгән. Шуңа өстәп мосхаф бүгенге көндә гамәлдә булган халыкара стандартларны да исәпкә алачак. Камил хәзрәт сүзләренчә, бу проект Рәсәйне Ислам дөньясының тулы хокуклы бер өлеше булып торуын күрсәтә. Шул рәвешле, кулъязма мосхаф илебезнең Коръәнне өйрәнү һәм Ислам дин гыйлеме фикере өчен фәнни кыйммәткә ия һәм каллиграфия сәнгате әсәре буларак та әһәмиятле булачак.

Кулъязма мосхаф әзерләүнең әһәмиятенә тукталып, ул каллиграфия мәктәбенең эшләвен Коръәнгә хезмәт итүдән башка күз алдына да китереп булмавы турында әйтте. «Мөселман каллиграфының рухи максаты – шәмаил ясауда түгел, ә нәкъ менә Мосхаф Шәриф әзерләүдә», – диде мөфти.

Камил хәзрәт Сәмигуллин Рәсәй мөселманнарының Коръән әзерләү буенча бай тарихы хакында сөйләгәндә, 1803 елда Казанның «Азия» типографиясендә мөселманнар тарафыннан әзерләнгән беренче басма Коръәнне искә ала. «Казан басмасы» дөньякүләм танылу ала, күп тапкырлар басылып чыга, әмма галимнәр арасында басмада киткән хаталар буенча бәхәсләр тынмый. Әлеге җитешсезлекләр өстендә эшләү һәм «Казан басмасы»н кабаттан нәшер итү өчен, 1909 елда Казанга 300 мөселман галиме җыела, алар арасында Әхмәдһади Максуди, Шәйхелислам Хәмиди, Муса Бигиев була. Җыелыш нәтиҗәләре буенча Муса Бигиевнең «Тасхих ресми хат» китабы дөнья күрә. Әлеге китап чыкканчы «Казан басмасын»дагы төгәлсезлекләр турында Шиһабетдин Мәрҗанинең «Фәваид әл-Мүһиммә» хезмәте дә дөнья күргән була. Шул рәвешле, тарихтан күренгәнчә, күп еллар барган бәхәсләр нәтиҗәсендә, Рәсәйнең танылган мөселман галимнәре Коръән бастыру методологиясен булдыра! Моннан тыш, Камил хәзрәт билгеләп үткәнчә, кулъязма мосхафта Коръән әзерләүнең дөньякүләм стандартлары да исәпкә алыначак, битләрнең, юлларның санына игътибар ителәчәк – ул гарәп булмаган укучыларга Коръән укуны

һәм ятлауны җиңеләйтә. Шулай итеп, кульъязма мосхаф Рәсәй дини мирасын өйрәнү нәтиҗәсендә әзерләнгән каллиграфия сәнгате әсәре булачак. Мосхаф фәнни әһәмияткә дә ия: ул Ислам каллиграфиясендә югалган Рәсәй-мөселман традицияләрен торгызуда беренче адым.

Мөфти хәзрәтнең чыгышыннан соң тантаналы өлеш башланды – Изге Коръәннең беренче сүрәсе «Фатиха» каллиграфик ысул белән язылды. Бу җаваплы эшне проектның төп башкаручысы – Казан каллиграфы Артур Писаренко башкарды. Ул Рәсәй ислам институты каршындагы «Ән-Намир әл-Мухаттат» гарәп каллиграфиясе һәм ислам сәнгате үзәге директоры Рамил Насыйбулловның шәкерте. «Фатиха» сүрәсе Раббыбызның Берлеген, Кодрәтен раслый, шулай ук кешеләр бәхетенә юл күрсәтә. Башка сүрәләр кебек үк, «Фатиха» «бисмилләһ»тән башлана. Шул рәвешле, мөселманнарның һәр эше бисмилләһ белән башланып киткән шикелле үк, Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулу елы да бүген Аллаһы исеме белән ачылды.

Шунысы игътибарга лаек, кульъязма мосхафлар әзерләү тәҗрибәсе бүгенге көндә Согуд Гарәбстаны, Төркия, БГӘ, Бәһрәйн, Кувәйт, Катар, Ливия, Марокко һәм Пакыстанда бар. Хәзер бу эшкә Казанда да керештеләр. Тегеләр яки бу сүзләрне төгәл һәм хатасыз язар өчен, Казан белгечләренә беренчел чыганакларга, фәнни тикшеренүләргә мөрәҗәгать итәргә, һәр хәрефне һәм авазны кат-кат тикшерергә туры киләчәк. Шул ук вакытта, мосхафта сүзләрне һәм хәрефләрне дөрес һәм сәнгати итеп язудан тыш, аларны ачык һәм аңлаешлы итеп язу турында да онытмаска кирәк, чөнки гарәп булмаган укучылар гарәп язуын аңламаска мөмкин. Әлеге эшкә консультант сыйфатында Дубайдан дөньякүләм танылган мөселман галиме, дин әһеле, Дубайның Коръән әзерләү комиссиясе (DIHQA) башлыгы, хафизлыкның иң югары дәрәҗәсенә ия булган, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең нәсел дәвамчысы шәех Мәэмүн Әр-Рави җәлеп ителде. Әлеге галимнең моңа охшаган проект белән идарә итү тәҗрибәсе бар. Моннан тыш, комиссиягә Рәсәйнең башка төбәкләреннән һәм чит илләрдән белгечләр керде.

dumrt.ru сайтыннан

# Җәннәттән җиргә төшерелү



Фото: shutterstock.com

*(Башы алдагы санда)*

Иблис Аллаһы Тәгаләгә итагать итмәде, тәкәбберләнеп, Адәм галәйһиссәламгә сәҗдә кылудан баш тартты. Хатасын аңлап, тәүбә итәсе урынга, Кыямәт көненә кадәр кешеләрне адаштырырга вәгъдә бирде. Шул рәвешле, Иблис бөтен кешелеккә дошман булды.

Адәм галәйһиссәламнән соң, Аллаһы Тәгалә Хавва радыяллаһу ганһәне халык кылды, ул аны Адәм галәйһиссәламнең кабыргасыннан яратты һәм икесен дә нигъмәтләре белән тулып торган җәннәткә кертте, аларны зурлады. Тик бер агачка якын килмәскә, аның җимешен ашамаска кушты.

Бу урында Иблис үз хәйләсен эшкә җикте: Адәм белән Хавваны, бу агачның җимешен ашаган очракта, җәннәттә мәңге калачаксыз, дип ышандырды. Аның максаты – бу гамәлне кылдырып, аларны Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтеннән мәхрүм итү, җәһәннәмгә кертү иде. Әмма Адәм белән Хавва, Иблистән аермалы буларак, хата кылуларын аңлауга ук, бик нык үкенеп, Раббыбыздан гафу итүен сорадылар, ихластан тәүбә кылдылар. Аллаһы аларның ихласлыкларын күреп, тәүбәләрен кабул итте һәм җәннәттән – җиргә төшерде.

Шул рәвешле, аларның җир йөзендәге тормышы башланды, балалары туды. Бу урында Кабил һәм Һабилнең кыйссасын искә төшереп үтик.

## Адәм галәйһиссәламнең уллары – Кабил һәм Һабил

Һабил кечкенәдән итагатьле, мәрхәмәтле бала булып үсте, ә Кабил, киресенчә, дорфа, усал иде. Беркөнне алар Аллаһы Тәгаләгә корбан китерделәр, әмма бары Һабилнеке генә кабул булды, чөнки ул корбанлыгын кызганмыйча, Аллаһы ризалыгы өчен, дип китерде, ә Кабил бу гамәлен саранланып, теләмичә башкарды. Монда да Иблис, явызлык кылыр өчен, мөмкинлекне кулдан ычкындырмады: Кабилнең күңеленә нәфрәт салды һәм ул туганы Һабилне һәлак итте. Бу җир йөзендә кылынган беренче гөнаһ иде.

Билгеле бер вакыт үткәч, Адәм галәйһиссәлам дә бу дөньядан китте. Ул беренче булып халык кылынган, беренче булып бу җир йөзендә тормыш алып бара башлаган: җир сөргән, утырткан, уңыш җыеп алган кеше иде. Үзенең белгәннәрен ул балаларына да өйрәтеп калдырган. Аларга яхшылык кылырга, яманлыктан ерак булырга, шайтан вәсвәсәсенә иярмәскә өндәгән.

Адәм галәйһиссәлам кыйссасы Коръәни Кәримдә күркәм рәвештә искә алынган.

Сәхифәне **Айсылу ЮЛДАШЕВА** әзерләде

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
№ 01 (318) гыйнвар, 2022 | җөмәдәл-әүвәл – җөмәдәл-ахыр, 1443

# ИСЛАМ ДИНЕНЕҢ ИДЕЛ БУЕНА ҮТЕП КЕРҮЕ ҺӘМ ТАРАЛУЫ

**Ислам тарихының Идел буендагы беренче сәхифәләре VII – X гасырларда төрки кабиләләрнең көчле дәүләтләреннән саналган Хазар каганлыгыннан башлана. Ул Алтай тауларыннан Карпаткача булган җирлектәге төрки һәм башка халыкларны берләштереп торган Төрки каганатның таркалуы нәтиҗәсендә VII гасырда формалаша.**

Хазарлар дәүләте территориясе башта Төньяк Кавказның тау алды районнары һәм Каспий диңгезе ярлары белән дала тигезлекләрен, көнбатышта Иделнең түбән өлеше, көнчыгышта Дон буйларын биләсә, әкренләп каганат Урта һәм Түбән Идел буена, төньякта Ока буйларына кадәр, көнбатышта империянең иң көчле чорларында Днепрга кадәр җәелә; Азов буйлары, Кырым ярымутравының күп өлеше һәм Керчен бугазының ике яры да каганатка буйсына торган була. Хазарларга, аланнар, черкеслар һәм Төньяк Кавказның башка кабиләләреннән кала, Идел Болгарстаны һәм Киев Русе дә буйсына. Хазарларның элеккеге башкалалары – Бәләнҗәр һәм Сәмәндәр – Терек елгасыннан көньяктарак урнашкан булса, VII гасырның урталарына башкала Идел буендагы хәзерге Әстерханнан төньяктарак урнашкан Итил шәһәренә күчә.

Хазарлар, болгарлар, бортаслар, маҗарлар әлеге күпмилләтле дәүләтнең төп төрки телле өлешен тәшкил итә. VIII гасыр башында Византиядән куылып, каганатта сәяси сыену тапкан яһүдләр, сан ягыннан күп булмасалар да, халыкның шактый йогынтылы, абруйлы өлешен тәшкил итә. Хазар каганатында төрле конфессия вәкилләре үзләренең дини мәнфәгатьләрен тормышка ашыра алган. Ислам диненең хазарлар дәүләтенә үтеп керүе VII гасырда ук гарәп миссионерлары һәм сәүдәгәрләреннән башлана. Ләкин дин шактый вакыт түбән социаль төркемнәр, гарәп һәм хорезм сәүдәгәрләре дине буларак кына яши. VII гасырның икенче яртысы – VIII гасыр башында гарәп-хазар яулары һәм гарәп гаскәр башлыгы Мәрвәнә бине Мөхәммәднең уңышлы сәяхәте нәтиҗәсендә каһан Ислам динен кабул итә, шул сәбәпле хазарлар җәмгыятендә җиңүчеләр алып килгән дин тизрәк тарала башлый. Хазарлар дәүләтендә диннең тотрыклануы Урта Азиядән каһанлыкка күченеп килгән хорезмлылар төркеменә бәйле була. Алар башкалада мәчет һәм мәдрәсә төзеп куялар.

Күренекле гарәп географы Әбү Исхак Әл-Истахри болай дигән: «Шәһәрдә (Итил) 8 меңнән артык мөселман яши, 30 мәчет бар. Каһанлыкның аз өлешен яһүдләр, күпчелеген мөселманнар һәм насаралар тәшкил итә; мәҗүсиләр дә бар».

X гасыр уртасына хазарлар Киев Русе, Идел Болгарстанын контрольдән ычкындыралар, Керчен бугазы тирәләрен югалталар. Азиядән килгән бәҗәнәкләр, көчәйгәннән көчәя барган Киев Русенә каршы көрәш нәтиҗәсендә болай да таркала барган империя тагын да көчсезләнә.



Фото: shutterstock.com

**«Ислам дине нигезләре»**
китабыннан

# ИСЛАМ ДИНЕ БҮГЕНГЕ ДӨНЬЯДА

2022 нче ел Татарстан һәм Рәсәй тарихына олы вакыйга буларак кереп калачак. Моннан 1100 ел элек, 922 елның 21 маенда, Рәсәй Федерациясендә яшәүче татарларның болгар бабалары, Ислам динен рәсми рәвештә кабул итеп, югары үскән мөселман цивилизациясенең бер өлешенә әверелде.

Пәйгамбәребез вакытында ук гарәпләр белән күрше халыкларга тарала башлаган Ислам динен бүгенге көндә дөньяның 120 дәүләтендә яшәүче 2 миллиардка якын кеше тота. Дөнья халкының чиреге, 25% ка якыны – мөселманнар дигән сүз бу! 28 илдә (Согуд Гарәбстаны, Мисыр, Марокко, Иран, Ирак, Күвәйт, Пакыстан һ.б.) Ислам дәүләт дине буларак кабул ителгән, 35 илнең халкы (Төркия, Урта Азия дәүләтләре, Казахстан, Әзербәйҗан һ.б.) башлыча мөселманнардан гыйбарәт.

Ислам динен кабул иткән урта гасыр дәүләтләре тиз арада югары үскән фән һәм мәдәният үзәкләренә әвереләләр. Фәлсәфә, дин белеме, медицина, математика, астрономия кебек дөньяви фәннәр өлкәсендә эшләгән Җәләлетдин Руми, Гомәр Хәйәм, Әл-Фараби, Ибне Сина, Таҗетдин Болгари, Әл-Хәрәзми, Әл-Бируни, Мәхмүд Кашгарый кебек гарәп, фарсы, болгар галимнәренең фундаменталь хезмәтләре хәзерге фәннәрнең чишмә башын, нигезен тәшкил итә.

**Фаяз ХУҖИН,**
археолог,
тарих фәннәре докторы



Фото: Islamic Culture Forum журналыннан

САДЫЙК ЙОШИО ИМАИДЗУМИ ТОКИО МӘЧЕТЕНДӘ ТӨРЕК СОЛДАТЛАРЫ БЕЛӘН

# ЙОШИО ИМАИДЗУМИ: ЯПОНЛЫНЫҢ ИСЛАМ ДИНЕН КАБУЛ ИТҮЕ

БИК АЗ КЕШЕ ГЕНӘ ЯПОНЛЫЛАРНЫҢ ИҢ БЕРЕНЧЕ ТАПКЫР ИСЛАМ ДИНЕ БЕЛӘН ТАНЫШУЫ ҺӘМ ИСЛАМ ДИНЕН КАБУЛ ИТҮЛӘРЕ БИРЕДӘ БУЛГАН ТАТАР ҖӘМӘГАТЬЧЕЛЕГЕ ЯРДӘМЕНДӘ БУЛГАНЫН БЕЛӘ

*(Дәвамы. Башы алдагы санда)*

Япониядә йөз елдан артык мөселманнар яши. 2016 елда алган мәгълүматларга караганда, илдә 120 000 тирәсе чит ил мөселман кешесе бар, шуларның 10 000 е җирле мөселман японлылары. Әмма бик аз кеше генә японлыларның иң беренче тапкыр Ислам дине белән танышуы һәм Ислам динен кабул итүләре биредә булган татар җәмәгатьчелеге ярдәмендә булганын белә. Бу мәкаләдә без сезне, нәсыйхәтчесе һәм укытучысы Габдерәшит хәзрәт Ибраһимов булган, Садыйк Йошио Имаидзуми белән таныштыруны дәвам итәбез.

## ИКЕНЧЕ БӨТЕНДӨНЬЯ СУГЫШЫННАН СОҢ

Садыйк Имаидзуми Япониягә кайтканнан соң, сугыштан кайткан кеше дучар була торган төрле авырлыклар алдында калган. Әмма бар кыенлыкларны да җиңеп, инженер-механик белгечлегенең тәҗрибәсен һәм белемен кулланып, «Митсубоши Индастриал Компани Лимитед» дип исемләнгән шәхси заводын ачып җибәргән һәм анда президент булган. Нигез салган компаниясе машиналар һәм оекбашлар әзерли торган җиһазлар җитештергән. Завод Токионың Итабаши районындагы Накадзюку (Харадзюку) кварталында урнаша. Аның даими сатып алучылары Япониянең сугыштан соң булган оккупация көчләре була.

## ЯПОНИЯ МӨСЕЛМАННАРЫНЫҢ БЕРЛӘШҮЕ

Садыйк Имаидзуми Япония һәм чит ил мөселманнары белән элемтәдә тора. Күпмедер вакыттан соң, аның элемтәләре ныгый. Компаниядә эшләүдән тыш, Садыйк Имаидзуми буш вакытын башка мөселманнар белән аралашуга багышлый. Ул японлы мөселманнарны берләштерүдә һәм аларның карашларын ныгытуда зур роль уйный. Садыйк Имаидзуми Япония Мөселманнары җәмәгатенә нигез салучыларның һәм җәмәгать әһелләренең берсе була.

Үз бизнесыннан тыш, ул Япония юстициясе министрлыгының штаттан тыш хезмәткәре дә була һәм элеккеге хөкем ителгәннәрне яклау һәм аларга киңәшче булу ролен үти. Үзенең эшләре бик тыгыз булу: компания белән идарә итү, җирле халыкка ярдәм күрсәтүгә дә карамастан, Садыйк Имаидзуми беркайчан да дини вазифаларын калдырмый. Япония мөселманнары җәмәгатьчелеге президенты буларак, аңа төрле чаралар үткәрергә кирәк була. Мәсәлән, чит илдәге Ислам университетларында укучы японлы яшь мөселманнарга стипендия түләүне оештыру, Япониянең төрле регионнарында лекцияләр үткәрү һәм анда чыгыш ясау, массакүләм мәгълүмат чаралары белән әңгәмә үткәрү яки, японлыларны Ислам дине белән таныштыру максатыннан, мәкаләләр язу.

Аның бертуктамый тырышлык куюлары белән, Япония мөселманнарының саны арта һәм 1959 елда, Япония Мөселман җәмәгатенең нигез салынуына 7 ел үткәннән соң, җәмәгать әгъзаларының саны берничә дистәгә җитә.

Әмма бервакыт Садыйк Имаидзуминың сәламәтлеге начарлана һәм ул авырып китә. Табиблар аның ашказанында яман шеш тапканнан соң, хастаханәгә ятарга киңәш итәләр. Әмма ул хастаханәгә ятудан баш тарта һәм үзенең вазифаларын үтәүне дәвам итә. Ләкин күпмедер вакыттан соң, кисәк кенә аның хәле начарлана һәм Садыйк Имаидзумины хастаханәгә салалар. 1960 елда, үзе белем алган Нихон университеты хастаханәсендә аңа операция ясала, тик инде соң була. 1960 елның 17 нче маенда Садыйк Йошио Имаидзуми фани дөньядан китә. Бу вакытта аңа 55 яшь була.

Аллаһы Тәгалә аны мәрхәмәтеннән аермаса иде.

**Дамир ГАЙНЕТДИНОВ** язмасы,
islam-today.ru сайтыннан тәрҗемә

# ЯУЛЫК – АЛЛАҺЫНЫҢ БҮЛӘГЕ

**Аллаһы Тәгалә бернәрсәне дә юкка гына әмер итмәде һәм бернидән дә болай гына тыймады. Һәр әмергә, тыюга хикмәт, Аның рәхмәте салынган. Коръәни Кәримдә:**

*«Күренгәннәреннән [йөз, аяк һәм кул чукларыннан] башка [капланылуы тиеш булган беләзек, аяк беләзеге, алка һәм муенса кебек] бизәнгечләрен күрсәтмәсеннәр...»,* – дип әйтелгән.
*«Ән-Нур», 24:31*


Фото: shutterstock.com

Харам ризыклар сәламәтлегебез өчен зыянлы булганга тыелган кебек, хатын-кызның гаурәтен каплавы, шәригатьчә киенүе дә аның иминлеге өчен мөһим булганга фарыз кылынган. Тарихка күз салсак, хатын-кыз беркайчан да хәзерге заман киенү рәвешендә йөрмәгән. Һәр халыкның үз гореф-гадәтләрен белдерә торган, аларның горурлыгы булган милли киемнәре булган. Кызганычка, билгеле сәбәпләр аркасында, алар тора-бара көнкүрештән төшеп калган, хатын-кыз булдыра алганча ачык, кыска, сыланып тора торган киемнәр киюгә ияләшкән һәм моны бер дә тарсынмыйча гадәткә керткән.

Бүген Коръән кушканча киенү рәвешен бер сүз белән «гарәпчә киенү» дип әйтәләр һәм шәригатьчә киенгән хатын-кызны татарча киенмәүдә гаеплиләр, хәтта тәнкыйтьлиләр. Әлбәттә, моны әйтүчеләр үзләре, гомумән, шәригатьчә дә, үзләре әйтмешли «татарча» да киенмәгән хатын-кызлар. Мөслимәләр буларак безнең максат – бу тәнкыйтькә күркәм рәвештә, булдыра алганча хикмәт белән җавап кайтару, чөнки дорфалык белән җавап биргән очракта, без кешегә, берни дә төшендерә алмаячакбыз һәм аларда яулыкка, мөслимәләргә һәм Ислам диненә карата дөрес булмаган күзаллау барлыкка килергә мөмкин. Шуны аңласак һәм башкаларга да аңлата алсак иде: шәригатьчә киенү – Коръәнчә киенү, ягъни Аллаһы Тәгалә кушканча киенү ул.

Әйе, без дә үзебезнең милли киемнәребезне булдырырга, элек мөселман татар хатын-кызлары кигән үрнәк буенча киенергә телибез, без әкренләп моңа кайтабыз да. Әмма бу зур тырышлык таләп итә, чөнки күп еллар дәвамында барган хатын-кызны шәригатьчә киенүдән тайпылдыру күренеше тиз генә уңай якка алышынып бетә алмый. Бүген безнең Аллаһы кушканча киенә, шул рәвешле теләгән җиребезгә бара алуыбыз, монда тыюлар булмау – ул инде Аллаһының рәхмәте булып тора. Шуңа да Аллаһы Тәгаләнең бу бүләген тиешле дәрәҗәдә кабул итеп, аңа тиешле игътибар бирсәк иде. Яулык – күркәмлек, тыйнаклык ул. Аның үз шартлары, тәртибе, хәтта хикмәте бар. Яулык кием генә түгел, ул рухи халәт тә. Шушы хәзинәне саклап, киләсе буынга – кызларыбызга, сеңелләребезгә дә тапшыра алсак иде.

**Айсылу ЮЛДАШЕВА**

## Дөрес булганга өйрәнү

Берьюлы Хәсән Әл-Басри кабер янында елап торучы бер кызны күргән. Ул:

– Ий әтием! Һәр кичне мин сиңа кичке аш әзерли, сиңа урын җәя идем. Кем хәзер сиңа боларны эшли инде? – дип өзгәләнгән.

Хәсән Әл-Басри аңа: «Болар урынына мондый сүзләр әйт: «Ий әтием! Без сине кыйблага каратып яткырган идек. Син шул халәттә калдыңмы? Яки сине икенче якка бордылармы? Ий әтием! Синең өчен кабер нәрсәгә әйләнде: җәннәт бакчасынамы яки җәһәннәм чокырынамы? Ий әтием! Син Мөнкир вә Нәкирнең сорауларына дөрес итеп җавап бирә алдыңмы?»

Кыз бала Хәсән Әл-Басриның әлеге сүзләрен ишетеп:

– Йә олы кеше! Син бик тә дөрес әйттең, – дип әйтә.

Һәм әлеге нәсыйхәтне кабул итә.

**Нәсыйхәт:** Кабер – бу дөнья тормышының соңгы баскычы, Ахирәт тормышының беренче баскычы булып тора. Ул дөньядан мәңгелеккә күчүне белдерә. Кабердә адәм баласы белән ул дөньяда үзен ничек тотуына карап эш итәчәкләр.

Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кабер кеше өчен йә җәннәт бакчаларыннан бер бакча яки җәһәннәм чокырларыннан бер чокыр булачак», – дип әйткән.

## Дөрес булмаган теләк

Бер тәкъва кеше Аллаһыдан шәйтанны күрсәтүен сораган. Аның танышлары: «Аллаһыдан иминлек сора. Шәйтанны күрсәң нишләрсең?» – дигәннәр. Әмма әлеге кеше аларның сүзләренә колак салмаган. Аллаһы Тәгалә аның болай соравына җавап итеп, шәйтанны күрсәткән. Шәйтанны күргән кеше аңа сугарга теләгән. Мәлгунь аңа: «Әгәр сиңа тагын 100 ел яшәү язмаган булса, мин сине, гамәлең өчен җәза буларак, һичшиксез, һәлак итәр идем», – дигән. Шәйтанның сүзләренә алданган кеше: «Минем әле озын гомер кичерәсем бар икән, шуңа күрә хәзер ни теләсәм – шуны кылыйм, ә аннары тәүбә кылырмын», – дип уйлаган. Бу рәвешле әлеге кеше гыйбадәтләрен калдырган, гөнаһлы гамәлләргә күчкән, һәм, ахыр чиктә, үлгән.

**Нәсыйхәт:** Бу кыйсса көчле теләкләрдән сак булырга кирәклеген аңлата, чөнки алар куркыныч. Адәм баласы Аллаһыдан иминлек сорарга һәм мәгънәсез теләкләрдән ерак булырга тиеш. Шәйтанның кешене алдый торган бик күп хәйләләре бар. Шуларның берсе – ул кешене алдау. Әгәр кеше берәр яхшы гамәл кылырга яки Аллаһының әмерен үтәргә җыенса, шәйтан шунда ук аңа вәсвәсә кыла башлаганын беләбез.

**«Рухуль Бәйан»** китабыннан

# РӘГАИБ КИЧӘСЕН ИСКӘ АЛЫП

**РӘГАИБ КИЧӘСЕ – УЛ ИЗГЕ РАҖӘБ АЕНЫҢ БЕРЕНЧЕ ҖОМГАСЫНА КАРШЫ БУЛГАН МӨБАРӘК КИЧӘ. БУ КИЧӘ АЛЛАҺЫНЫҢ РАСҮЛЕ – МӨХӘММӘД САЛЛӘЛЛАҺУ ГАЛӘЙҺИ ВӘ СӘЛЛӘМНЕҢ ӘТИСЕ ХӘЗРӘТИ ГАБДУЛЛА БЕЛӘН ӘНИСЕ ХӘЗРӘТИ ӘМИНӘНЕҢ НИКАХЫ БУЛЫП, ТӘҮГЕ ТАПКЫР КАВЫШКАН КӨНЕ ДИП ӘЙТЕЛӘ**

Пәйгамбәребез үзе үк бу төн турында болай дип әйткән: «Рәҗәб аеның беренче җомгасына каршы төнне ваемсызлыкта үткәрмәгез, чөнки бу төнгә фәрештәләр Рәгаиб дип исем кушканнар». «Рәгаиб» сүзе гәрәпчәдән – «теләкләр», «өметләр» дип тәрҗемә ителә. Шуңа күрә аны «теләкләр, догалар кичәсе» дип тә атап булыр иде. Гомумән, һәрвакыт күңелдә яхшы теләкләр, ниятләр һәм өметләр белән яшәү мөселман кешесенең әхлагы булып тора.

Рәгаиб кичәсен искә алу безнең өчен Пәйгамбәребез белән бәйле булганы өчен дә бик якын, чөнки Пәйгамбәребез безнең өчен олы үрнәк. Аның белән бәйле булган вакыйгаларны искә алып, без дөньябыз һәм Ахирәтебез өчен зур файдалар алабыз. Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әтисе хәзрәти Габдулла белән әнисе хәзрәти Әминәнең кавышып гаилә коруы һәм шуның сәбәбендә Пәйгамбәребезнең дөньяга килүе – гаиләнең, ир һәм хатын булуның, гаилә җимешләре – балаларның булуы, Аллаһының безгә карата рәхмәте һәм тормыш кануны икәнен аңлата. Җиһанда һәрбер әйбернең парлы булып яратылуында, аларның бер-берсен тулыландырып, парлы булуында күп файдалар һәм тормыш рәхәте ачыла. Бәндәнең дә парлы булып, бер-берсенә ярдәмче, терәк, бер гаилә булып яшәве сәбәбендә, аңа тормышның күп кенә нигъмәтләрен күрү, аларга ирешү насыйп була, Ахирәттә аның дәрәҗәләре арта.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

---

*«Бергә яшәвегез өчен үзләрегездән сезнең өчен хатыннар яратуы һәм арагызда сөю [нәтиҗәсендә хасил булган бердәмлек] белән бер шәфкать [чарасы булган бала] бирүе дә – Аның билгеләреннән. Һичшиксез, монда уйлаганнар өчен [аңлатылып бетерә алмаслык дәрәҗәдә зур] билгеләр бар».*

*«Әр-Рум / Румлылар», 30:21*

*«Алар – сезгә кием һәм сез – аларга кием».*

*«Әл-Бәкара / Сыер», 2:187*

---

Бу аятьләрдән аңлашылганча, ир белән хатынның бер гаилә булып никахлашып яшәве – Аллаһы Тәгаләнең кануны. Ир һәм хатын, ата һәм ана, бала, әби һәм бабай булу бәхете һәм гаилә бәхете – барысы да Аллаһы Тәгаләнең бәндәләргә бу дөньялыкта биргән нигъмәтләреннәндер. Ошбу канунны бозып, башка төрле яшәү рәвеше булдырырга тырышу, кеше өчен, җәмгыять өчен бик зыянлы һәм һәлакәткә илтә, бу очракта кеше үзе теләп, Аллаһының рәхмәтеннән ваз кичә. Кеше дөньялыгында да, Ахирәтендә дә бәхетсез була. Шушы рухи кыйммәтләрне саклау һәм аларны үстерү, аларга чакыру динебезнең бер максаты булып тора. Хәзерге вакытта да бу мәсьәлә бик актуаль булып кала. Динебезгә, халкыбызга хас булмаган, гаилә кыйммәтләрен җимерә торган, ата-ана төшенчәсен түбәнсетә торган ялган кыйммәтләр турында ишетергә, шундый яшәү рәвешен алга сөрүне очратырга туры килә.

Никах – ул Аллаһы Тәгалә каршында сүз, ант биреп килешү төзү. Һәм бу килешүгә игътибарлы булу, аны саклау ошбу килешүне төзүчеләрнең бурычы.

Берәү, хатыныннан зарланырга дип, хәлифә Гомәр радыяллаһу ганһе янына барган. Килеп җитсә, хатыны Гомәр радыяллаһу ганһене пыр туздырып әрләп маташа, ә ул дәшми генә тыңлап тора икән. «Моның хәле минекеннән мөшкел икән», – дип, теге кеше кире борылып киткән. Гомәр радыяллаһу ганһе аның артыннан куып җитеп: «Ни йомыш иде?» – дип сораган. «Хатынның холкыннан зарланып килгән идем, синең хәл дә мактанырлык түгел икән, ничек сабыр итәсең?» – дип сораган теге кеше.

Хәзрәти Гомәр радыяллаһу ганһе: «Хатыным мине зинадан саклый, ашарга әзерли, киемнәремне юа, өйне тәртиптә тота, балаларымны тәрбияли. Ничек инде мин аннан риза булмыйм?! Аллаһы Тәгалә хатын-кызга акылны ирләргә караганда кимрәк, хисне артыграк биргән. Җавап кайтарсам, аңа караганда да акылсызрак булам бит», – дип җавап биргән.

Гаилә төзек булсын өчен һәр кешенең үз урыны булу шарттыр. Шушы урында Гәбделхәбир хәзрәт Ярullinның ир һәм хатын вазифалары турында әйтелгән сүзләрен җиткерәсем килә: «Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Бурычларга килсәк, хатын-кызның ике төп бурычы бар: Беренчедән, ул гаиләдәге җитәкченең акыллы киңәшчесе. Өйдә җитәкче – ир кеше һәм соңгы сүзне ул әйтергә тиеш. Хатын-кыз моны аңласа, әйтә алмый торган йомшак ир кешедән дә нык фикерле җитәкче ясый ала. Әгәр тели икән, ул моңа ирешә ала, юк икән, «Үзем эшлим, үзем башкарам», – дип, ир өстеннән таптап чыгып китә. Мондый гаиләнең таркалуын көт тә тор инде. Кечкенә генә бу сәясәтне хатын-кыз аңларга тиеш.

Хатын-кызның икенче бурычы: балаларына хәерле ана булу. Ул боларны үти алдымы, аңа башка зур таләпләр куярга, вак-төяккә бәйләнергә кирәкми.

Ә ир кешенең бурычы күбрәк. Ул гаиләдә җитәкче. Һәр җитәкченең төп вазифасы – үзенең хуҗалыгын саклау һәм үстерү. Димәк, ир кеше гаиләне саклау һәм үстерү турында уйларга тиеш, шулай ук хатын ашсу бүлмәсендә генә калмасын, укысын, гыйлем эстәсен, кирәк тапса, эшләсен. Балалар тәртипле, әдәпле, дини яктан иманлы булып үссен өчен, нигездә, ана җаваплы».

Раббыбыз безгә матур тормыш итәргә боера. Гаилә кешегә бу мөмкинлекне бирә. Бәхетле гаилә – җирдә җәннәтнең чагылышы булып тора. Аллаһы Раббыбыз безгә тигезлектә гомер итәргә насыйп кылсын.

**Инсаф хәзрәт ИБАТУЛЛИН,**
«Динислам» мәчете
имам-хатыйбы



*Гөлсинә*
*ГАЛИМУЛЛИНА*

# *Кояшлы дала кызы*

*(Повестьтән өзек.*
*Башы алдагы санда)*

– Бишебез дә аралашып яшибез: оныкларың өчен дога гына кыл, дәү әни! – диде Айрат, тигез ак тешләрен җемелдәтеп.

...Табын яныннан кузгалгач, Венераның әнисен ялгыз йортта үзен генә калдырасы килмәде, үзләренә чакырды. Әнисенең икеләнеп торганын күргәч:

– Балалар барысы да Казанга китәләр, өйдә Ринат белән икебез генә калабыз.

– Чакыруыңа рәхмәт, бүген бармыйм әле, оныклар белән аралашудан алган күңел җылымда җылынып утырасым килә. Әйдә, үзең минем янымда калып тор, – диде.

Ана белән кыз үзара сөйләшкән арада, берсеннән-берсе чибәр, озын буйлы ир солтаннары булып җитлеккән оныклары, затлы итеп киенгән киленнәре, оныкчыклары китәргә җыенды.

– Әти-әнигез белән дәү әниегез – сезне көтеп яши, улларым, киленнәрем, оныкчыкларым! Кайтып йөрегез, бәхет ачкычының башы – төп нигез җылысында икәнен, исегездән чыгармагыз, – дип, Сания һәрберсе белән кочаклашып чыкты.

Оныклары ничек гөрләшеп килеп кергән булсалар, шулай итеп чыгып та киттеләр. Сания аларны озаткач, юл догасы укыды. Машина тавышлары тынганчы, тәрәзә аша күзен юлдан алмады...

... Венера белән Ринат олы диванга, Сания алар каршындагы кәнәфигә утырды. Әле кайчан гына кызы колагына пышылдап кына: «Өченче оныгың да булачак!» – дигән иде. Инде Азат та үсеп җитеп, үзе әти булды. «Нәсел дәвам итә, бик яхшы хәбәр җиткердең», – дип, кызының карынына кулын куйганын, туачак баланың иманлы-тәүфыйклы булуын теләп, дога кылганын исенә төшерде.

– Сара кайнанам: «Тормыш юлы буйлы-буйлы, берсе кара, берсе ак. Карада чакта бирешмә, карадан соң килер ак, – дия иде. Узган гомер юлыма борылып карыйм да, исем китә! Баттым – тордым: тормыш юлымны дәвам иттем. Әби-бабайдан, әти-әнидән калган хәер-дога, аларның безгә биргән дөрес киңәшләре яшәтте. Әти еш кына: «Кызларым, бәхетне кулга тотып карап булмый, бәхет ул – һәрвакыт алга омтылу. Туктап калырга ярамый, белемегезне гел өстәп торыгыз», – дияргә ярата иде. – Әти безгә сүзен үтемле итеп җиткерә белгән. Аның сүзләрен мин үз балаларыма сеңдереп үстердем. Сездән оныкларыма җиткерелде. Биш онгыбыз да югары уку йортында белем алды. Җәмгыять өчен кирәкле кешеләр булдылар. «Балаңнан чын Кеше ясыйм, дисәң, ата-ананың үзендә акыл запасы киң булырга тиеш!» – дия иде әни. – Уйлап карасаң, кайсын искә төшерсәң, шул юк. Әти-әниемне, ике иремне, улымны, Галимә апаны, аның биш баласын, ике апамны, аларның ирләрен мәңгелек йортка озаттым. Барысы да бер йөрәк аша узды, әле дә үз акылымда мин, – дип көлемсерәп куйгач, Венера:

– Сиксән бишенче яшен түгәрәкләп килүче әбинең, оныклары белән яшь кеше кебек гәп корып утыруын, шаккатып тыңладым әле. Айратны Әлмәт районына глава итеп куйгач, эшләре белән бик каты кызыксына башлагач: «Менә сиңа ноутбук, инстаграмда #любимыйальметьевск дигән аккаунтка керәсең һәм безнең эшләр белән танышып торырсың», – дип, биш ел элек, туган көненә ноутбук бүләк итеп биргәч, өйрәнә алуыңа ышанмаган идем. Менә бит, яшьләр белән рәттән барасың. Шушы яшеңдә компьютер белән эшләргә өйрәнә алу – бу зур җиңү, әни! Миңа да Аллаһ синең яшеңдә зирәк акыл бирсә иде, дип сорыйм.

Әнисе, кызы белән киявенә яратып карады. Аннары баш миен ничек итеп яңартып торырга кирәклеген әйтеп күрсәтте:

– Аллаһка якын булу, гыйбадәт кылып яшәү, Коръән уку, интернетта үз яшең өчен кирәк санаган төркемнәрдәге яңалыклар белән танышып тору, «Азбука Корана» һәм «Тайна здоровье» газеталарын даими уку, буыннар, йөрәк, тын юллары өчен көн саен махсус гимнастика ясау, көн саен саф һавада бер мең адым җәяү йөрү... – дип, санап китте.

Венера белән Ринат әниләренең һәр сүзен йотып алырдай булып тыңладылар. Ике буын вәкиле бер-берсен аңлап, тулыландырып, туганнарын искә төшереп, кояш баеганчы сөйләшеп утырдылар. Ул арада Венера ике тапкыр чәй яңартты, уллары алып килгән тәмле-тәмле ризыклар белән сыйландылар.

...Кызы белән киявен озаткач та, Сания ятарга ашыкмады. Бүгенге көнен тагын бер кат күз алдыннан үткәрә башлады. Кайсы нинди сүз әйткәнен исенә төшерде. Ринат кияве – гаҗәеп акыллы кеше. «Бабайлардан килгән акыл хәзинәсен син безгә дөрес итеп җиткерә белдең, әби. Малайлар да шул сүзләрне ишетеп үсте. Бабайның: «Белемеңне даими арттырып тору – үзе алга омтылу», – дигән сүзе белән килешәм. Югары уку йортын тәмамладым дип кенә, әлбәттә, белемең артмый, баш программаңны яңартып тормасаң», – дип әйткән сүзен исенә төшереп, кызының гомере акыллы ир белән үткәненә куанды.

Сания башын йомшак мендәренә салды. Күңеле Аллаһка тоташты. «Раббым, әти-әнием кечкенә чагымда мәрхәмәтләре белән үстергәннәре кебек, Син дә аларга рәхимле бул. Оҗмахларыңда күрешергә насыйп ит», – дип, көн дә кабатлый торган догаларын укый-укый, йокыга китте. Төшендә оныкларының үзенең бакчасында алмагачлар утыртканнарын күреп, елмаеп уянды...

*(Дәвамы киләсе санда)*

## ДҮШӘМБЕ, ЧӘРШӘМБЕ, ҖОМГА

| | |
|---|---|
| 07:00 | Онлайн-мәдрәсә |
| 07:30 | «Рухуль-Бәйан» |
| 07:35 | Тәмле булсын |
| 07:55 | Татарлар тарихы |
| 08:35 | «Иң гүзәл исемнәр» |
| 08:45 | Имамнан сорыйк |
| 09:30 | Дин турында |
| 10:00 | Гыйбрәтле хикәяләр |
| 10:15 | Хәдис дәресләре |
| 10:35 | «Ислам мәдәниятенең алтын гасыры» |
| 10:45 | «Шөкер хуҗа» анимацион фильмы |
| 10:55 | «Сүз эчендә хикмәт бар» |
| 11:05 | Намазга өйрәник (ирләр өчен) |
| 11:30 | Вәгазь вакыты |
| 12:00 | Азан |
| 12:05 | «Энциклопедия для маленьких мусульман» |
| 12:10 | «Детская зарядка» |
| 12:15 | «Узнаем у имама» |
| 13:00 | История Ислама в России |
| 13:20 | Золотой век исламской цивилизации |
| 13:30 | «Такой татарский русский» |
| 13:35 | «Шекер Ходжа» анимационный фильм |
| 13:45 | Стереотипы об исламе |
| 14:00 | «Татарская география» |
| 14:05 | Халяль-лайфстайл |
| 14:20 | «Хузур-вояж» Антон Кротов белән. Яңа сезон! |
| 14:30 | Фәнни-танып-белү фильмы |
| 15:00 | Нәфис сериал |
| 16:00 | Онлайн-мәдрәсә |
| 16:30 | «Рухуль-Бәйан» |
| 16:35 | Тәмле булсын |
| 16:55 | Татарлар тарихы |
| 17:35 | «Иң гүзәл исемнәр» |
| 17:45 | Имамнан сорыйк |
| 18:30 | Дин турында |
| 19:00 | Гыйбрәтле хикәяләр |
| 19:15 | Хәдис дәресләре |
| 19:35 | «Ислам мәдәниятенең алтын гасыры» |
| 19:45 | «Шөкер хуҗа» анимацион фильмы |
| 19:55 | «Сүз эчендә хикмәт бар» |
| 20:05 | Намазга өйрәник (хатын-кызлар өчен) |
| 20:30 | Вәгазь вакыты |
| 21:00 | «Энциклопедия для маленьких мусульман» |
| 21:05 | «Детская зарядка» |
| 21:10 | История Ислама в России |
| 21:30 | Золотой век исламской цивилизации |
| 21:40 | «Такой татарский русский» |
| 21:45 | «Шекер Ходжа» анимационный фильм |
| 21:55 | Стереотипы об исламе |
| 22:10 | «Татарская география» |
| 22:15 | Халяль-лайфстайл |
| 22:30 | Фәнни-танып-белү фильмы |
| 23:00 | Нәфис сериал |
| 00:00 | «Хузур-вояж» Антон Кротов белән. Яңа сезон! |
| 00:10 | «Узнаем у имама» |
| 00:55 | Коръәни Кәрим укылышы (мәгънәви тәрҗемәләр белән) |

## СИШӘМБЕ, ПӘНҖЕШӘМБЕ, ШИМБӘ

| | |
|---|---|
| 07:00 | Онлайн-мәдрәсә |
| 07:30 | «Рухуль-Бәйан» |
| 07:35 | Тәмле булсын |
| 07:55 | Татарлар тарихы |
| 08:35 | «Иң гүзәл исемнәр» |
| 08:45 | Имамнан сорыйк |
| 09:30 | Дин турында |
| 10:00 | Гыйбрәтле хикәяләр |
| 10:15 | Хәдис дәресләре |
| 10:35 | «Ислам мәдәниятенең алтын гасыры» |
| 10:45 | «Шөкер хуҗа» анимацион фильмы |
| 10:55 | «Сүз эчендә хикмәт бар» |
| 11:05 | Намазга өйрәник (ирләр өчен) |
| 11:30 | Вәгазь вакыты |
| 12:00 | Азан |
| 12:05 | «Энциклопедия для маленьких мусульман» |
| 12:10 | «Детская зарядка» |
| 12:15 | «Узнаем у имама» |
| 13:00 | История Ислама в России |
| 13:20 | Золотой век исламской цивилизации |
| 13:30 | «Такой татарский русский» |
| 13:35 | «Шекер Ходжа» анимационный фильм |
| 13:45 | Стереотипы об исламе |
| 14:00 | «Татарская география» |
| 14:05 | Исламские финансы |
| 14:20 | «Хузур-вояж» Антон Кротов белән. Яңа сезон! |
| 14:30 | Фәнни-танып-белү фильмы |
| 15:00 | Нәфис сериал |
| 16:00 | Онлайн-мәдрәсә |
| 16:30 | «Рухуль-Бәйан» |
| 16:35 | Тәмле булсын |
| 16:55 | Татарлар тарихы |
| 17:35 | «Иң гүзәл исемнәр» |
| 17:45 | Имамнан сорыйк |
| 18:30 | Дин турында |
| 19:00 | Гыйбрәтле хикәяләр |
| 19:15 | Хәдис дәресләре |
| 19:35 | «Ислам мәдәниятенең алтын гасыры» |
| 19:45 | «Шөкер хуҗа» анимацион фильмы |
| 19:55 | «Сүз эчендә хикмәт бар» |
| 20:05 | Намазга өйрәник (хатын-кызлар өчен) |
| 20:30 | Вәгазь вакыты |
| 21:00 | «Энциклопедия для маленьких мусульман» |
| 21:05 | «Детская зарядка» |
| 21:10 | История Ислама в России |
| 21:30 | Золотой век исламской цивилизации |
| 21:40 | «Такой татарский русский» |
| 21:45 | «Шекер Ходжа» анимационный фильм |
| 21:55 | Стереотипы об исламе |
| 22:10 | «Татарская география» |
| 22:15 | Исламские финансы |
| 22:30 | Фәнни-танып-белү фильмы |
| 23:00 | Нәфис сериал |
| 00:00 | «Хузур-вояж» Антон Кротов белән. Яңа сезон! |
| 00:10 | «Узнаем у имама» |
| 00:55 | Коръәни Кәрим укылышы (мәгънәви тәрҗемәләр белән) |

## ЯКШӘМБЕ

| | |
|---|---|
| 07:00 | Онлайн-мәдрәсә |
| 07:30 | «Рухуль-Бәйан» |
| 07:35 | Тәмле булсын |
| 07:55 | Татарлар тарихы |
| 08:35 | «Иң гүзәл исемнәр» |
| 08:45 | Имамнан сорыйк |
| 09:30 | Дин турында |
| 10:00 | Гыйбрәтле хикәяләр |
| 10:15 | Хәдис дәресләре |
| 10:35 | «Ислам мәдәниятенең алтын гасыры» |
| 10:45 | «Шөкер хуҗа» анимацион фильмы |
| 10:55 | «Сүз эчендә хикмәт бар» |
| 11:05 | Намазга өйрәник (ирләр өчен) |
| 11:30 | Вәгазь вакыты |
| 12:00 | Азан |
| 12:05 | «Энциклопедия для маленьких мусульман» |
| 12:10 | «Детская зарядка» |
| 12:15 | «Узнаем у имама» |
| 13:00 | История Ислама в России |
| 13:20 | Золотой век исламской цивилизации |
| 13:30 | «Такой татарский русский» |
| 13:35 | «Шекер Ходжа» анимационный фильм |
| 13:45 | Стереотипы об исламе |
| 14:00 | «Татарская география» |
| 14:05 | Исламские финансы |
| 14:20 | «Хузур-вояж» Антон Кротов белән. Яңа сезон! |
| 14:30 | Фәнни-танып-белү фильмы |
| 15:00 | Нәфис сериал |
| 16:00 | Онлайн-мәдрәсә |
| 16:30 | «Рухуль-Бәйан» |
| 16:35 | Тәмле булсын |
| 16:55 | Татарлар тарихы |
| 17:35 | «Иң гүзәл исемнәр» |
| 17:45 | Имамнан сорыйк |
| 18:30 | Дин турында |
| 19:00 | Гыйбрәтле хикәяләр |
| 19:15 | Хәдис дәресләре |
| 19:35 | «Ислам мәдәниятенең алтын гасыры» |
| 19:45 | «Шөкер хуҗа» анимацион фильмы |
| 19:55 | «Сүз эчендә хикмәт бар» |
| 20:05 | Намазга өйрәник (хатын-кызлар өчен) |
| 20:30 | Вәгазь вакыты |
| 21:00 | «Энциклопедия для маленьких мусульман» |
| 21:05 | «Детская зарядка» |
| 21:10 | История Ислама в России |
| 21:30 | Золотой век исламской цивилизации |
| 21:40 | «Такой татарский русский» |
| 21:45 | «Шекер Ходжа» анимационный фильм |
| 21:55 | Стереотипы об исламе |
| 22:10 | «Татарская география» |
| 22:15 | Исламские финансы |
| 22:30 | Фәнни-танып-белү фильмы |
| 23:00 | Нәфис сериал |
| 00:00 | «Хузур-вояж» Антон Кротов белән. Яңа сезон! |
| 00:10 | «Узнаем у имама» |
| 00:55 | Коръәни Кәрим укылышы (мәгънәви тәрҗемәләр белән) |

**ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ**

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**

Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе **Камил СӘМИГУЛЛИН;**

«Хозур» нәшрият йорты директоры **Ришат ХӘМИДУЛЛИН**;

ТР МДНнең Шәригать бүлеге җитәкчесе **Булат МӨБАРӘКОВ;**

Татарстанның баш казые **Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**

ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы **Габдулла ӘДҺӘМОВ**

Баш мөхәррир: **Хамматов Л. Г.**
Мөхәррирләр: **Хәләфетдинова Л. Г., Юлдашева А. И.**
Яңартылган логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Шәйхетдинов А. Х.**
**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** shura@huzur

**Гамәлгә куючы:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**Нәшир:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт).
Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.

Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә. Заказ №2543.
График буенча бу санга 24 нче гыйнвар көнне 21.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде.
Кул куелды: 21.00 сәгатьтә.
Газетага ярты елга язылу бәясе – 140, 40 сум.
Индексы – П4333. Казан шәһәренең мәчетләрендә 25 нче гыйнвар таратыла.

# НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

## ФЕВРАЛЬ 2022 / КАЗАН

| Көн | Көн исеме | ИРТӘНГЕ НАМАЗ | | Кояш чыга | ЗӘВӘЛ | ӨЙЛӘ НАМАЗЫ | ИКЕНДЕ НАМАЗЫ | АХШАМ НАМАЗЫ / ИФТАР | ЯСТУ НАМАЗЫ |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Сәхәр тәмам | Мәчетләрә укыла | | | | | | |
| 01 | Сиш | 05:29 | 06:07 | 07:37 | 11:57 | 12:00 | 14:25 | 16:17 | 18:04 |
| 02 | Чәрш | 05:27 | 06:05 | 07:35 | 11:57 | 12:00 | 14:27 | 16:19 | 18:06 |
| 03 | Пәнҗ | 05:25 | 06:03 | 07:33 | 11:57 | 12:00 | 14:29 | 16:21 | 18:08 |
| 04 | Җом | 05:24 | 06:01 | 07:31 | 11:57 | 12:00 | 14:31 | 16:23 | 18:09 |
| 05 | Шим | 05:22 | 05:59 | 07:29 | 11:57 | 12:00 | 14:33 | 16:25 | 18:11 |
| 06 | Якш | 05:21 | 05:57 | 07:27 | 11:57 | 12:00 | 14:35 | 16:28 | 18:13 |
| 07 | Дүш | 05:19 | 05:55 | 07:25 | 11:57 | 12:00 | 14:37 | 16:30 | 18:15 |
| 08 | Сиш | 05:17 | 05:53 | 07:23 | 11:57 | 12:00 | 14:39 | 16:32 | 18:17 |
| 09 | Чәрш | 05:15 | 05:51 | 07:21 | 11:57 | 12:00 | 14:41 | 16:34 | 18:19 |
| 10 | Пәнҗ | 05:13 | 05:49 | 07:19 | 11:57 | 12:00 | 14:43 | 16:36 | 18:21 |
| 11 | Җом | 05:12 | 05:47 | 07:17 | 11:57 | 12:00 | 14:45 | 16:38 | 18:23 |
| 12 | Шим | 05:10 | 05:45 | 07:15 | 11:57 | 12:00 | 14:47 | 16:41 | 18:24 |
| 13 | Якш | 05:08 | 05:42 | 07:12 | 11:57 | 12:00 | 14:49 | 16:43 | 18:26 |
| 14 | Дүш | 05:06 | 05:40 | 07:10 | 11:57 | 12:00 | 14:51 | 16:45 | 18:28 |
| 15 | Сиш | 05:04 | 05:38 | 07:08 | 11:57 | 12:00 | 14:53 | 16:47 | 18:30 |
| 16 | Чәрш | 05:02 | 05:36 | 07:06 | 11:57 | 12:00 | 14:55 | 16:49 | 18:32 |
| 17 | Пәнҗ | 05:00 | 05:33 | 07:03 | 11:57 | 12:00 | 14:57 | 16:51 | 18:34 |
| 18 | Җом | 04:57 | 05:31 | 07:01 | 11:57 | 12:00 | 14:59 | 16:54 | 18:36 |
| 19 | Шим | 04:55 | 05:29 | 06:59 | 11:57 | 12:00 | 15:01 | 16:56 | 18:38 |
| 20 | Якш | 04:53 | 05:26 | 06:56 | 11:57 | 12:00 | 15:03 | 16:58 | 18:40 |
| 21 | Дүш | 04:51 | 05:24 | 06:54 | 11:57 | 12:00 | 15:05 | 17:00 | 18:42 |
| 22 | Сиш | 04:49 | 05:22 | 06:52 | 11:56 | 12:00 | 15:07 | 17:02 | 18:44 |
| 23 | Чәрш | 04:46 | 05:19 | 06:49 | 11:56 | 12:00 | 15:09 | 17:04 | 18:46 |
| 24 | Пәнҗ | 04:44 | 05:17 | 06:47 | 11:56 | 12:00 | 15:10 | 17:07 | 18:48 |
| 25 | Җом | 04:42 | 05:14 | 06:44 | 11:56 | 12:00 | 15:12 | 17:09 | 18:50 |
| 26 | Шим | 04:39 | 05:12 | 06:42 | 11:56 | 12:00 | 15:14 | 17:11 | 18:52 |
| 27 | Якш | 04:37 | 05:09 | 06:39 | 11:56 | 12:00 | 15:16 | 17:13 | 18:54 |
| 28 | Дүш | 04:34 | 05:07 | 06:37 | 11:56 | 12:00 | 15:18 | 17:15 | 18:56 |